**/Безнең спорт/**

### Чаңгы юлларында ешрак йөрик



Безнең илдә 1982-нче елдан башлап, һәр кыш саен «Россия чаңгы юллары» («Лыжня России») чарасы үткәрелеп килә. Массакүләм спорт чарасы булган бу бәйгедә ел саен 1,5 млн. тирәсе кеше катнаша. Чаңгыда шуу-спорт юнәлеше генә түгел, ә барлык балалар һәм өлкәннәр өчен дә күңел ачу чарасы да булып тора. Мондый чаралар кешеләрнең физкультура, сәламәт һәм актив яшәү рәвеше белән кызыксынуларын арттыруга ярдәм итә.

2021 елда «Россия чаңгы юллары» 13 февраль көнне үткәрелде. Бу көнне чаңгы ярышы безнең мәктәптә дә уздырылды. Әлеге ярышта барлык укучылар да диярлек катнашты. I-V сыйныфлар арасында 1-нче урынны – Гафиятуллин Фаил, 2-нче урынны – Залиева Вәсилә, 3-нче урынны – Хәбибрахманов Абдулла яулады. VI-IX сыйныфлар арасында, 1-нче урын – Хәбибрахманов Ильяска, 2-нче урын – Хәйруллин Айназга, 3-нче урын – Хәйруллин Данилга бирелде. Җиңүче укучылар мәктәп грамоталары белән бүләкләнде. Укычыларга теләгебез шул – **чаңгыда йөрү бер көн белән генә чикләнеп калмасын иде**. Физкультура дәресләрендә генә түгел, мәктәптән тыш вакытта да чаңгыда йөрү өчен мөмкинлек һәрберебездә дә бар.

### Көрәшләр булып узды



Ватанны саклаучылар көненә багышлап 21-нче февраль көнне Норлат шәһәрендә уздырылган билбау көрәше буенча ярыштан безнең укучылар зур уңышлар белән кайтты. IX сыйныф укучылары **Камалов Илдус** белән **Хәбибрахманов Ильяс** – 1-нче, II сыйныф укучылары **Замалетдинов Зөлфәт** белән **Хәбибрахманов Абдулла** 2-нче, VI һәм X сыйныф укучылары **Хәйруллин Айназ** белән **Нурматов Халит** 3-нче урыннарга ия булдылар.

25-27-нче февральдә Мамадыш шәһәрендә 2005-2008-нче елгы яшүсмерләр арасында татарча көрәш буенча ярышлар узды. Бу ярышта, безнең мәктәптән Хайруллин Айназ, Галимов Рияз һәм Камалов Илдус катнаштылар. Беренче көнне үлчәнү һәм тулай торакка урнашу булды. Икенче көнне көрәш уздырылды. Җиңүчеләр алдагы көнгә калып урыннар өчен көрәштеләр, көрәштән соң иң яхшылары бүләкләнде. Кызганычка каршы, безнең мәктәптән катнашучылар арасында призлы урын алучы булмады. Егетләргә осталыкларын тагын да арттырып, киләсе көрәшләрдә уңышлар теләп калабыз.

25-нче февраль көнне Болгар шәһәрендә 2006-2004-нче елгы егетләр һәм кызлар арасында билбау көрәше буенча Республик ярышы уздырылды. Монда һәр авырлыктан 3 урын алган көрәшчеләр, Татарстанның данын яклаучы булarак, Рәсәйкүләм ярышка барырга тиешләр иде. Болгардагы ярыш 3 көн дәвамында уздырылды. Безнең мәктәптән Хабибрахианов Ильяс һәм Нурматов Халит 55 кг авырлыкта көрәштеләр. Җиңүчеләр өчлегенә кермәсәләр дә, алар үзләренә күп тәҗрибә алдылар.

Көрәшчеләрне тәрбияләүче һәм төрле ярышларга йөртүче остаз **Камалов Илһам абыйга** зур рәхмәтләребезне белдерәбез.

### Фаил тагын беренче

Ватанны саклаучылар көне уңаеннан 22-нче февраль көнне Чистай шәһәрендә шахмат буенча блиц-турнир үткәрелде. Безнең мәктәп данын күп тапкырлар яклаган **Гафиятуллин Фаил** бу ярышта да, көндәшләрен җиңеп, беренче урынны алуга ирешә.

***Рубриканы IX сыйныф укучылары Хәйруллин Данил белән Хәбибрахманов Ильяс әзерләде***

**/Күңелле тәнәфес/**

### Тизәйткечләр

Сокланам мин Сабирга,
Сабир кебек сабырга.
Сабирдагы сабырлык
Сабыр хәйран калырлык.

Эшләп ашаган кешегә
Таш та аш.
Эшләмичә ашаганга
Аш та таш.

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева  Сара Насыйрова
Виктория Нукина  Рузилә Мөхәммәтова
Зөлфирә Сафиуллина

# Мәктәп хәбәрчесе

№2 (№23) февраль 2021 ел
Түбән Майна урта мәктәбе газете
Тел. 8 (84344) 4-38-46  sch1644maina@mail.ru

**Газитнең бу санын IX сыйныф укучылары әзерләде**

**/Өлкәннәр киңәше/**

### Һөнәр сайлау җиңелме?

Татар халкында шундый мәкаль бар: «Агач яфрагы белән, кеше хезмәте белән күренекле». Бу бик хак сүзләр һәм моның белән килешмәүчеләр дә бик сирәктер. Чөнки кеше хезмәт иткәндә генә үзендә нинди сыйфатлар яшеренгәнен күрә ала. Хезмәт кешегә материаль байлык кына китерми, ул аны бизи, шатлык та китерә әле. Синең эшең үзеңә охшаса, хезмәт нәтиҗәләрең башкаларга файда китерсә, сиңа карап кемнәрдер үрнәк алса – шунардан да куанычлырак ни бар тагын?

Безнең халык элек-электән хезмәт сөючәнлеге белән аерылып торган. Ата-аналар балаларын кечкенәдән эшкә өйрәткәннәр, башкаларның хезмәтенә хөрмәт тәрбияләгәннәр. «Эшләгәнең кеше өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен» ди халык мәкале.



Февраль ае чыгарылыш сыйныфлар өчен бик җаваплы вакыт. Бу айда укучыларның чыгарылыш имтиханнарын сайлавы тәгәлләнә. Әле чыныгып җитмәгән, акыллары “утырмаган” балаларга бик зур сынау бу. Чөнки киләчәкне кузалларга, җәмгыятьтә үз урыныңны табу өчен нинди юллар сайларга, һәм башка җаваплары әлегә булмаган бик күп сораулар...

Баланың нәрсәгә сәләтле булуын, күңеле нинди хезмәткә күбрәк тартылганын ата-аналар, укытучылар тиз күреп алырга тиешләр дип уйлыйм. Ә андый сәләтләр кайчан, кайсы вакытта күренә соң. Баланың сәләте сыйныфта дәрес вакытында гына түгел, ә күбрәк уеннар уйнаганда, төрле түгәрәкләрдә, сыйныфтан тыш эшләр эшләгәндә, әти-әниләр белән балаларының бергә сәяхәтләре вакытында, йорт эшләренә булышканда ачыклана.

Кызганычка каршы, соңгы елларда урамда балаларның шау-шулы уеннары, әти-әниләр белән бергәләп сәяхәтләр оештыру, мәктәптә булган чараларда актив катнашу бик сирәгәя бара. Чөнки балаларыбызны телефоннан, интернет челтәреннән аерап алу бик нык кыенлашты. Тәнәфестә уеннар уйнау теләге юк – кулда телефон, буш вакыт булдымы – телефон. Юлда барганда да кырлар-урманнарны карап бармыйлар. Чөнки кулда телефон – атыш уйныйсы бар. Кичләрен гаиләдә китап укып, әкиятләр сөйләшеп утырырга вакыт җитми – телевизорда “кызык” бара, яки ютубка кереп чумабыз. Ә кайчан соң балаларга җәмгыятьтә үз юлларын табарга, нинди хезмәт күңелгә якын икәнен ачыкларга? *(Дәвамы 2-нче биттә)*

### 23 февраль – Ватанны саклаучылар көне белән дуслар!




23-нче февраль Ватанны саклаучылар көне булырак бәйрәм итәлә. Ватан – ул бик гомумиләштергән сүз. Бу сүзне әйткәндә без туган җиребезне, гаиләләребезне, әти-әни, туганнарыбызны күздә тотабыз. Һәр бала шулар-ны истә тотып, Ватанны саклаучы булырга әзерләнеп үсәргә тиеш. Ә мондый бурыч күбрәк ир балалар җилкәсенә төшә.

Безнең мәктәптә бәйрәм хөрмәтенә егетләр арасында хәрби-спорт ярышлары булып үтте. Алар ике төркемгә бүленеп көч сынаштылар. Ә кызлар исә егетләрнең җитезлекләрен күзәтеп, катнашучыларга көч биреп тордылар. Бәйге бик күңелле, оешкан төстә үтте. Төрле эстафеталар, автомат җыю, противогаз киеп йөгерү, аркан тарту кебек ярышларда барлык егетләр дә үз көчләрен кызганмадылар. Ярышлар тәмамлангач жюри нәтиҗәләр белән таныштырды. Ярышта Илсаф командасы өстен чыкты.

Мәктәптә укучы барча малайларны һәм эшләүче абыйларны Ватанны саклаучылар көне белән котлыйбыз! Без сезгә ышанабыз, егетләр!



***IX сыйныф кызлары***

## Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы чаралары

21 нче февраль дөньякүләм дәрәҗәдә Халыкара туган телләр көне буларак билгеләп үтелә. Әлеге дата һәм Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы уңаеннан 20 нче февраль көнне мәктәп күләмендә чара үткәрелде. Бәйрәм чаралары башлангыч һәм V-VI сыйныф укучылары тарафыннан әзерләнгән иде. Иң беренче булып укучылар "Аулак өй" чарасын күрсәттеләр. Бу тамашаның төп идеясы элеккеге гореф-гадәтләрне искә төшерү булды. Яшь кызлар һәм малайлар йолаларны бик яхшы күрсәттеләр. Шунан соң III сыйныф укучысы Закирова Ләйсән "Зөһрә кыз" әкиятен сөйләде. Ул аны бик оста, сәнгатьле итеп башкарды. Ахырдан укучылар рус халык әкияте "Гуси и Лебеди"ны сәхнәләштерделәр.

Барлык балалар да кичәгә нык тырышлык белән әзерләнгәннәр. Кичәне оештыруда башлангыч сыйныф укытучылары Гафиятуллина Зөлфия, Камалова Сирин, Хайруллина Рузилә, ӘЗакирова Гөләат апалар һәм рус теле укытучысы Назмутдинова Рушания апаның өлеше бик зур булган. Балалар барлык рольләрне дә җиренә җиткереп, төгәл итеп үтәргә тырыштылар.

***Әминә Туктамышева, IX сыйныф укчысы***

## Аксубай техникумында очрашу



19-нчы февраль көнне, без IX сыйныф малайлары, Аксубай универсаль технологияләр техникумына очрашуга бардык. Анда төрле елларда шул уку йортын бетеручеләр, хәзерге студентлар, район мәктәпләренең IX сыйныф укучылары очраштылар.

Сәяхәтебезне тулай торак бинасыннан башладык. Бу бина заманча таләплар буенча җиһазландырылган. Бүлмәләр якты, җылы, укучылар өчен барлык уңайлыклар да бар. Студентлар өчен ял, юыну, кер юу бүлмәләрен күреп сокландык. Аннан китеп техникумның уку бинасына юнәлдек. Безне заман таләбенә туры килә торган температура һәм автомат зарарсызландыра торган кабиналар таң калдырды. Уку бүлмәләре шулай ук яхшы җиһазланган. Уку-өйрәнү өчен барлык мөмкинлекләр дә бар. Ашханә үзе бер могҗиза.

Сәяхәтнең икенче өлеше зур залда узды. Анда район җитәкчесе Гилманов Камил Камал улы да катнашты. Беренче булып ул барлык катнашучыларны якынлашып килүче Ватанны саклаучылар көне белән котлады, техникум исеменә җылы сүзләр җиткерде. Бу уку йорты директоры Аюпов Фәрхат Фоат улы техникум белән кыскача таныштырды. Нинди белгечлекләр буенча әзерләүләрен сөйләде. Барлык катнашучыларны да бүләкләр белән сөендерделәр. Котлаулар концерт номерлары белән үрелеп барды. Соңыннан ашханәдә студентлар пешергән тортлар белән сыйландык.

Техникумда укучылар өчен яхшы мөмкинлекләр булуына без тагын бер кат ышанып кайттык. Бәлки кем дә булса шунда һөнәр алырга барыр да әле. Анысын вакыт күрсәтер.

***Илдус Камалов, IX сыйныф укучысы***

## Математика атналыгы

15-нче февральдан алып 20сенә кадәр безнең мәктәптә математика атналыгы игълан ителде. Бу атнада бик кызыклы конкурслар һәм уеннар әзерләнде. Бәйгеләрнең барысын да – Резедә апа һәм Фәнил абый уздырдылар. Алар безгә: стена газетасы чыгару (9-11 сыйныфлар), математик башваткычлар төзү (7-8 сыйныфлар), "Үрнәк эш дәфтәре" (5-8 сыйныфлар), "Математик фантазия" рәсем ясау, "Математическая шкатулка" (5-6 сыйныфлар) тәкъдим иттеләр. Фәнил абый 7 нче сыйныфларга "Математик башваткыч"- дигән уен уздырды. Шулай ук ул безгә "Судоку"- диеп аталган уен турында сөйләде һәм аны ничек уйнарга икәнен өйрәтте. Иң актив һәм яхшы эшләүче укучылар бүләкләр белән бүләкләнделәр.

***Зөлфирә Сафиуллина, IX сыйныф укучысы***

*(Башы 1-нче биттә)*

Хөрмәтле әти-әниләр. Балаларыбызның укуда булган уңышларын күреп без барыбыз да бик сөенәбез. Тормышта да без үстергән, без тәрбияләгән балалар үз урыннарын тапсыннар иде. Үзләренә охшаган, күңелләренә якын булган һөнәрләр үзләштерсеннәр иде. Яратып эшләгәндә генә яхшы нәтиҗәгә ирешеп була. Игенчеме син, очучымы, тәрбияче әллә депутатмы, нефтьче яки диңгезчеме, ил сакчысы я булмаса төзүчеме – кем булуы мөһим түгел – үз эшеңнең остасы бул. Син эшне түгел, ә эш сине үзе эзләрлек булсыннар иде балалар. Шул урында Муса Җәлил сүзләрен искә аласы килә:

Мин күп күрдем филдәй кешеләрне:
Киң күкрәкле, тимер бәдәнле.

Тик күрәсе иде эше белән
Кеше булган иң чын адәмне.

Чыннан да, үзенә бер шөгыль тапмаган, тырышлык куймаган, нинди дә булса һөнәр сайламаган кешегә яшәү кызык та түгелдер ул. Хезмәт сөйгән кеше генә тормышта үз урынын таба ала.


***Рифкать Туктамышев, IX сыйныф җитәкчесе***



## Элеккеге хисап (арифметика) дәресләкләрендә китерелгән дөреслекне тикшерү ысуллары

Гәзитнең алдагы саннарында элеккеге мәктәп-мәдрәсәләрдә кулланылган хисап (арифметика) дәреслекләре турында мәкаләләр бастыра башлаган идек. Бу санда **"Бәдруль-хисәб" (Хисапның беренче адымы)** дәреслеге белән таныштырып китәргә булдык. Әлеге китап хисап гыйлеменә кереш рәвешендә язылган. Авторы – Мәмсә авылы имамы Сабирҗан Габделбәдиг мулла улы. Китапның 3-77 битләре сакланган. Титул битенең аскы өлеше ертылганлыктан, басылу елын белү мөмкин түгел. Тел үзенчәлекләреннән чыгып исәпләгәндә, китап 1880-1890 елларда басылган һәм кулланылган кадими мәктәп дәреслеге булып тора.

Башка дәреслекләрдән аермалы буларак, бу китапта сумманың һәм тапкырчыгышның дөреслеген тикшерүнең үзенчәлекле ысуллары (мизан) китерелә. Шундый мизаннарның берсе 9га кимету ысулы дип атала. Моның өчен кушылучы саннардагы цифрларны кушып, тугыздан арткан саен тугызга кимәтә барырга кирәк. Аннан соң шул ук гамәлне суммадагы цифрлар белән дә эшләргә. Әгәр сызык өстендә һәм астында нәтиҗә бертөсле чыкса, мисал дөрес эшләнгән була.



"Бәдруль-хисәб" дәреслегендә тапкырлау таблицасы

Мисал:
687
<u>235</u>
922

<u>6 + 8 = 14;  14 – 9 = 5;  5 + 7 = 12;  12 – 9 = 3;  3 + 2 + 3 + 5 = 13;  13 – 9 = **4**</u>

9 + 2 = 11;  11 – 9 = 2;  2 + 2 = **4**

Шундый ук ысул тапкырчыгышның дөреслеген тикшерү өчен дә тәкъдим ителә. Моның өчен башта вакланма язгандагы кебек бер сызык сызыла. Сызыкның уң ягына өскә тапкырланучы санның 9га киметкәннән соңгы калдыгы, ә аның астына тапкырлаучының шундый ук калдыгы языла. Аннан соң бу ике калдык тапкырланып, килеп чыккан тапкырчыгышы янә 9га кимételеп, калдыгы сызыкның сул ягына, өскә языла. Аның астына 9га кимételгән тапкырчыгышның калдыгы языла. Әгәр сызыкның сул ягындагы калдыклар тәңгәл килсә, җавап дөрес була.

Мисал:
746
<u>358</u>
5968
3730
<u>2238</u> .
267068

<u>**2**</u> <u>8</u>
**2** 7

7 + 4 = 11;  11 – 9 = 2;  2 + 6 = **8**.   3 + 5 + 8 = 16;  16 – 9 = **7**.   8 × 7 = 56

<u>56 – 9 = 47;  47 – 9 = 38;  38 – 9 = 29;  29 – 9 = 20;  20 – 9 = 11;  11 – 9 = **2**</u>

2 + 6 + 7 = 15;  15 – 9 = 6;  6 + 6 = 12;  12 – 9 = 3;  3 + 8 = 11;  11 – 9 = **2**

Әлбәттә, әлеге тикшерү ысулларын гади дип атап булмый. Шулай да, күп урынлы саннар белән эшләгәндә авырсынучы укучыларга аны тәкъдим итеп карарга була.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***





21-нче февраль көнне мәктәбебезнең әйдәп баручы укытучыларыннан булган **Хәсәнова Ризидә апаның** гомер бәйрәме. Бу айда (25.02), шулай ук безнең мәктәптә әле күптән түгел генә эшли башлаган **Закирова Гөлшат апаның** да туган көне. Хөрмәтле укытучылар! Сезне чын күңелдән туган көннәрегез белән котлыйбыз. Яшь буынны тәрбияләүдә башкарган хезмәтләрегез өчен Сезгә зур рәхмәт. Алдагы тормышыгызда исәнлек-саулык, тыныч тормыш, эшегездә иҗади уңышлар телибез.

Февраль аенда дөньяга килгән балалардан, бакча төркеменнән **Камалов Илнурны** (10.02.), II сыйныф укучылары **Донсков Артурны** (08.02 ) һәм **Хәбибрахманов Абдулланы** (03.02), IV сыйныф укучысы **Хусенов Стасны** (27.02), V сыйныф укучылары **Минакова Ләйлә** (26.02) белән **Йосыпов Рәсимне** (14.02), VIII сыйныф укучысы **Сидоров Романы** (20.02) туган көннәре котлыйбыз. Тырышып укыгызны, тәрбияле балалар булып үсүегезне теләп калабыз.